| МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

21.11.2025 Казан ш № 739

2026 елда балигъ булмаганнарга һәм эшсез гражданнарга аларны вакытлыча эшкә урнаштыру чорына финанс ярдәме күләмнәре турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 9 августындагы 553 номерлы һәм «Татарстан Республикасы мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы белән вакытлыча характердагы түләүле эшләрдә яисә түләүле җәмәгать эшләрендә катнашу чорында гражданнарга финанс ярдәме күрсәтү тәртибен раслау турында» 2025 елның 30 апрелендәге 289 номерлы карарлары нигезендә боерык бирәм:

1. 2026 елга түбәндәге финанс ярдәме күләмнәрен билгеләргә:

14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру чорына бер кешегә аена 2650 сумга тигез күләмдә;

түләүле җәмәгать эшләрендә катнашучы эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру чорына бер кешегә аена 2650 сумга тиң суммада;

эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру чорына бер кешегә аена 2650 сумга тиң суммада;

Урта һөнәри белемле һәм белем турында документ бирелгән көннән алып бер ел дәвамында эш эзләүче, эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче 18 яшьтән 25 яшькә кадәрге эшсез гражданнарның вакытлыча эшкә урнашу чорына бер кешегә аена 4500 сумга тиң суммада;

гомуми белем бирү оешмаларын тәмамлаучылар арасыннан эшсез гражданнарга, аларга белем турында документ бирелгән көннән алып бер ел дәвамында, вакытлыча эшкә урнашу чорына бер кешегә 4500 сумга тиң суммада.

2. Әлеге боерык 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп тору буенча министр урынбасары К.А. Таҗетдинованы җаваплы итеп билгеләргә.

| Министр | ОТДЕЛ ДЕЛО-ПРОИЗВОДСТВА | Э.Ә. Зарипова |
|---|---|---|